

Унсигезенче тәрбия. Шәех Сәгъди сөйләгән икән: бер сәфәремез вакытында, ялда, төн урталарында уяныш китсәм, ни күзем белән күрим: бер юлдашыбыз, бер читтәрәк, җырлап-елап, шигырьләр әйтеп, күзен дә йоммастан төнне уздырды. «Бу ни хәл тагы?!» — дип сорадым. Әйтте: «Былбылларны күрдем: куактан-куакка очып, аһзар кылалар. Киекләр — таулардан әрнүле авазлар салалар. Бакалар — суда иңриләр. Төрле җанварларның шау-шуыннан урманнар гөрләп тора. Шундый фикергә килдем: барлык җан ияләре, киекләр, кошлар, йокламастан зикертәсбих әйткән бер вакытта, минем изрәп йоклап ятуым аңкаулык булмасмы?» — диде.

Бөтендөнья балалары, дуслашыгыз!



САБАНТУЙ

БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШҮСМЕРЛӘР ГАЗЕТАСЫ

15 декабрь, 1993 ел.
№ 100
(4506)



Күңелләрдә — төсләр дөньясы

МИН күбрәк зәңгәрсу төсләрне яратам. Зәңгәр күк йөзе, зәңгәрләнеп торган диңгез дулкыннары ясыйм. Иптәш кызларымны рәсемгә төшергәндә дә күлмәкләрен шундый төскә буйыйм.

Алсу аны «салкын төс» дип атый. Үзенең рәсемнәре гел алтынсу сары төсләрдән тора аның. Япякты кояш, сап-сары иген басулары, кызгылт-сары кыр чәчәкләре...

Ә менә Русланның өстәлендә буяу карандашларының гел караңгы төстәгеләре генә була. Төн куелыгын ясарга ярата ул, ерып чыккысыз шомлы, караңгы урманнарны, көзге яңгырлы төннәрне сурәткә төшерә...

«Монда һич тә аптырар нәрсә юк, — дип аңлата апабыз, — һәркемнең үз төсе, үз дөньясы булырга тиеш. Тормышның да төрле яклары була бит. Аны кем ничек кабул итә инде...»

Рәсемдә шулай. Тормышта исә гел якты төсләргә генә омтыла күңел. Якты күк йөзен, якты кояшны, якты йөзле апаларны, абыйларны яратабыз. Әниебезгә дә яктырып карыйбыз, ул да безне якты, нурлы күзләре белән иркәләп йоклата.

Күңелләребездәге аклык, йөрәкләребездәге пакьлек гел матур эшләргә генә әйдәсен безне.

Фоторәсемдә сез бу балаларның иҗат халәтен күрәсез.

К. ӘХМӘРОВ фоторәсеме.

* * *

ТАТАРСТАН Республикасы Балалар фонды Яңа ел алдыннан балалар өчен гадәти булмаган бүләкләр тәкъдим итәргә булды. Тәм-том тутырылган гадәти пакетларда быел тиз уйнала торган лотерея билетлары да булачак. Бәхетлеләрне 300 дән алып 1 миллион сумга кадәр акча, Диснейлендка (АКШ) путевкалар көтә.

* * *

КАЗАНДА яңа спорт сарае төзеләчәк. Ясалма боз аренасы булган әлеге бина дөнья стандартлары нигезендә һәм татар милли бизәкләрен кулланып төзеләчәк.

ДУЛКЫН-ДУЛКЫН ЯҢАЛЫК

* * *

РОССИЯ Президенты әмере белән Мәскәүдә В. И. Ленин үзәк музее ябылды. Музей хезмәткәрләренә бер ай эчендә 13 залдагы экспозицияне һәм җиһазларны сүтеп ташларга куштылар. Монда Мәскәү шәһәр Думасы урнашачак.

* * *

ТАТАР дәүләт җыр һәм бию ансамбле Мәскәүдә чыгыш ясады. Алар башкалада яшәүче милләттәшләребезгә күренекле татар композиторы Салих Сәйдәшев истәлегенә багышланган зур концерт программасы күрсәттеләр.

* * *

КАЗАН хакимиятенең мохтаҗ гаиләләрне социаль яклау идарәсе инициативасы белән балалар йортларындагы һәм интернатлардагы башлангыч класс укучыларына бүләк итеп мәктәп киемнәре бирелде.

БӘЙРӘМ ДИСӘҢ ДӘ БӘЙРӘМ

ТЕЛӘСӘҢ, гади генә бер көнне дә файдалы һәм күңелдә озак сакланырлык итеп уздырырга була икән.

Киров районында урнашкан 4 нче татар гимназиясендә укучы кызлар һәм малайлар өчен уку елының һәр көне әнә шундый бәйрәм. Шаянлар да, тырышлар да, җырга, биюгә дә оста алар. Ә менә 2 Б сыйныфында укучы гимназистлар барысыннан да уздырып җибәрделәр. Кечкенә булсалар да, гимназиядә узган бер генә концерт, кичә дә алардан башка узмый. Хәтта иртә белән укырга да алар иң беренче булып киләләр. Килүгә, баянчы Рафаэль абыйлары тирәсендә кайнаша башлыйлар. Дәресләр башланганчы әнә шулай бер рәхәтләнеп биеп, җырлап алалар. Укуда да алдынгы бу балалар. Ә инде дәресләр тәмамлануга барысы да түгәрәкләргә таралыша. Җырларга, биергә, матур итеп рәсем ясарга, музыка коралларында уйнарга, төрле кул эшләрен башкарырга да нәкъ әнә шул түгәрәкләрдә өйрәнәләр. Укытучылары Рушания апаларын да бик яраталар алар. Әле кайчан гына укырга, язарга өйрәткән укытучылары бүген аларны шәфкатьле булырга, олыларны ихтирам итәргә, яшьтәшләрен тиң күрергә өйрәтә, белемле булып үсүләрен тели.



Бу сыйныф балалары дус һәм тату да әле. Бертуганнар диярсең. Кечкенә генә вакыйга да бирелә бәйрәмгә әйләнә. Өстәл өстендә пар чыгарып утырган самавыр тирәсенә балалар белән бергә әти-әниләр, әби-бабайлар да җыела. Сөйләп сүзләр, җырлап җырлар бетми шул чакларда.

Әле күптән түгел генә алар Уңыш бәйрәме уздырдылар. Уку бүлмәсе дә, балаларның йөзләре дә бәйрәмчә иде. Шулай булмыйча, бу бит балаларның иң яраткан, көтеп алган бәйрәмнәре. Һәр җирдә — алтын сары яфраклар. Стенага үзләре ясаган рәсемнәрне элгәннәр. Аларда көзге урман да, яшелчә бакчасы да, анда үскән байлыклар да. Ә почмактагы өстәл өсте көзге байлыклар белән тулы. Бәрәңге, кишер, суган, кабак, чөгендер, баклажан, чикләвек, баланга кадәр бар иде анда. Аларның күбесен балалар җәйге каникулда авылда әби-бабайлары янында ял иткәндә үзләре үстереп алып килделәр.

Бергәләп рәхәтләнеп күңел ачтылар. Аннары Уңыш бабай балаларга үзенең бүләкләрен өләште. Әниләр дә бик уңган булып чыктылар. Бәйрәм табыны алар пешергән сыйдан сыгылып торды.

Гүзәл ЗӘЙНУЛЛИНА.
Казан.

МИН мәктәптәге «Оста куллар» түгәрәгенә бик теләп йөрим. Монда үземә ошаган кул эше белән шөгыльләнәм. Хезмәт укытучыбыз Равис абый җитәкчелегендә без бик күп төрле әйберләр ясарга өйрәндек. Өйдән агач материаллары алып килеп, кырып, буяп, лаклап, өстәл, балта сабы, пычак, урындык, уенчык машиналар, тракторлар, шәмдәлләрне бик оста итеп ясыйбыз. Хезмәт дәресе белән түгәрәк көннәрен яратып көтеп алам. Без остазыбыз Равис абый Дусадбеков ярдәмендә алдагы тормышларыбызда кирәкле булган бик күп нәрсәләрне үз кулларыбыз белән иҗат итәргә өйрәнәбез.

ЭШКӘ ӨЙРӘНӘБЕЗ

Илсур НӘБИУЛЛ[И]
Тукай, Иске Дөр

Мәгърифәт бездә кунакта

Исәнме, бабабыз! Әйе, әйе, син бабай бит безгә, «Сабантуй». Сиңа инде 70 булса, безгә әле 3 кенә. Беләсеңме, синең дусларың — безнең дуслар да. Шуңа күрә бүген без синең кунагың. Кунак тыйнак була, диләр. Озын-озак сөйләп тормыйча, уртак дусларыбыз колагына берничә генә сүз пышылдыйк әле.

Кадерле балалар! Сабый яшендә генә булсак та, безне өлкән абый-апаларыгыз да, яшьтәшләрегез дә яратып укыйлар. Мәзәкләр дисеңме, җырлар, башваткычлар, конкурслар дисеңме — бездә ни генә юк. Безнең белән дуслашу әллә ни авыр түгел. Әти-әниегездән 2034 сум сорап алып почта бүлегенә барсагыз яки апа-абыегызны җибәрсәгез — үзегезне «Мәгърифәт»нең дусты дип санагыз. Әгәр язылырга өлгермәгән булсагыз, хафаланмагыз, безгә ел дәвамында язылырга мөмкин. Индексыбыз — 54195.

Оныгың «МӘГЪРИФӘТ».



Ә. ШӘФИГУЛЛИН фоторәсеме.



* * *

Имтиханнан чыккан ике абитуриент сөйләшә:

— Син яза алдыңмы?

— Юк, биргән кәгазьләрен чип-чиста килеш тапшырдым.

— Юкка алай иткәнсез. Миннән күчергәнсез дип уйламагайлары...

* * *

— Фамилиягез? — дип сорый укытучы.

— Мөхетдинов, — ди студент авызын ерып.

— Ә нигә елмаясыз?

— Беренче соравыгызга чатнатып җавап биргәнем өчен.

* * *

Пөхтә генә киенгән яшь егет район китапханәсенә килеп:

— Монда мин укымаган китаплар бик аз калды, миңа берәр яхшырак китап сайлап бирә алмассызмы, — дип, китапханәче кызга мөрәҗәгать итә.

Китапханәче кыз:

— Салтыков-Щедрин әсәрләрен укыганыгыз бармы? — дип сорый.

— Салтыковны күп укыдым, Щедрин әсәрләрен бирегез, — дигән егет.

„Мин кечкенә карак"

Быел 11 нче класста укучы бу яшүсмер башкалардан бер ягы белән генә аерыла. Ул — кесә карагы. Марат мине күрүгә:

— Нигә сез минем турыда язарга телисез? Мин бит кечкенә карак, — диде.

— Син үзеңне кечкенә карак дип санйисыңмы?

— Билгеле. Башкалар миллионнар белән эш йөрткәндә.

— Миллионнарны урлауга караганда, кесә карагы булу җиңелрәктер?

— ...

— Әйдә, алайса, сөйләшүне башка төрлерәк башлыйк. Сезнең эш урыныгыз транспорттыр инде.

— Әйе.

— Үзең генә йөрмисеңдер...

— Бер төркем булабыз.

— Транспортка утырдыгыз, ди. Шуннан...

— Транспортта кеше күп вакытны сайлыйбыз. Күбрәк арттагы ишектән керергә тырышабыз. «Корбан»ны нинди социаль катлам вәкиле булуына карап сайлыйбыз. Күбрәк хатын-кызны. Интеллигент, таныш-белеше күп булган, гаугачыл хатын-кызга тимәскә тырышабыз.

— Ә таныш-белеше күп икәнен каян беләсез?

— Белеп була аны. Сизәргә була. ...Аннан соң сумканың нинди материалдан булуы да мөһим. Кисеп буламы?

— Сумка актарганда йөрәкләр кысыладыр?

— Беренче вакытларда гына. Куллар калтырый, йөрәк табан астына төшә. Ә аннан соң... Бер күнеккәч, үз кесәңнән көмеш тәңкәләр эзләгән кебек кенә була.

— Лезвиены кайда яшерәсез?

— Тел астына.

— ...

— Иң җайлы урын шул. Лезвиены дүрт өлешкә бүләбез дә...

— Бармак арасына кыстыруларын ишеткәнем бар иде.

— Мин сезгә үз эш алымнарымны гына сөйлим.

— Аңладым. Шулай да нигә тел астына. Берәр нәрсә килеп чыкса, ташлыйсың гына бит. Кем белә аның син ташлаганын.

— Нәкъ менә ташламаска кирәк. «Эш коралын» үзгәртү — барысын да яңадан башлау белән бер. Бер лезвие белән гел эш пешә. Ә алыштырсаң, эшләр киregә китүе бар. Була бит шундый җайлы эш кораллары...

— Керем нинди була? Бүлешәсезме?

— Әйе. Керем төрлечә. Кармак салгандагы кебек. Я бер дә эләкми, я чуртан эләгә, я вак-төяк...

— Шулай да, Марат, кемнеңдер күңеле елый, сыкрый бит. Үзеңне таланган кеше хәленә куеп кара әле.

— Берни дә хис итмим. Чөнки алар да кемнеңдер урлый, без аларны һәм безне дә алдыйлар.

Алдыйбыз һәм алданабыз. Сез: «Юк, мин алдамыйм»,— диярсез. Ә мин әйтәм, алдыйсыз дип. Менә әле генә як-ягыгызга карана-карана трамвайдан төштегез. Талон тиштермичә. Алдадыгыз бит. Төштегез дә тукталыштагы киоскка барып шоколад сатып алдыгыз һәм алдандыгыз. Сатучы шоколад бәясен хуҗасы әйткән бәядән 10 сумга артыграк куйган иде. Сез трамвай талонына кызганган ун тәңкәгә ул да мохтаҗ икән бит...

Н. ГАРИПОВА.

„Каралама" почтасы

* * *

ДУСТЫМ, «Каралама»! Сиңа йөрәктәге әрнүләремне, күңелдәге борчуларымны язам. Сиңа язам, чөнки мине тыңлардай, аңлардай башка кеше юк.

Мин шигырьләр язу белән мавыгам. Юк, шагыйрә булырга теләп түгел. Алар күңелдә үзләреннән-үзләре туа. Аннан дәфтәргә язып куям. Шундый бер дәфтәр тутырдым инде. Минем мондый гадәтем барын авылда берәү дә белми иде. Быел яз көне, сер итеп кенә, татар теле һәм әдәбият укытучыбыз Галия апага шигырь язуымны әйттем. Ул: «Шигырьләреңне бир. Укып чыгармын да сиңа киңәшләр бирермен», — диде. Белсәгез иде, ничек шатланганымны. Шатлыгым эчемә сыймаслык булса да, беркем белән дә уртаклашасым килмәде. Оялдым. Шигырьләр язуымны кешегә әйтергә дә оялам мин. Ә Галия апаның: «Киңәшләремне бирермен», дию, мине җиде кат күккә менгергән иде. Тик, инде көз җитте, укулар башланды. Ләкин әле Галия апаның киңәшләрен ишеткәнем юк. Үзен күргән саен: «Галия апа, шигырьләремне укымадыгызмы, әле?» — дип сорыйм. «Юк әле, үскәнем, менә шушы арада укырмын», — ди. Гел бер сорау, гел бер җавап. Ярты ел вакыт үтеп бара инде. Тагын кайчанга кадәр вәгъдә итәр икән? Бу кадәр игътибарсызлык, хөрмәтсезлек, мәгънәсезлеккә күпме түзәргә мөмкин?

Л. С.
Әлки районы.

* * *

ИСӘНМЕ, «Каралама»! Сиңа хат язарга булдык әле. Без гаиләдә ике кыз. Сеңлем 1 нче класста, мин өченче класста укыйм. Үзара бик тату, дус яшибез. Иң яраткан уеныбыз — «курчаклы» уйнау. Курчакларыбызны «ашатабыз», «йоклатабыз». Аларга киемнәр тегәбез. Бик күңелле уен. Әмма әни генә гел орышып тора. Өйне туздырасыз, ди. Әзрәк көлешә, сөйләшә башласак, «Кычкырышмагыз әле!» дип ачулана. Ачуланып кына да калмый, кайчак кыйнап та ташлый. Ә безнең уйныйсы килә. Шундый кызык, рәхәт бит уйнавы. Ә үзләре, әти белән икесе, кычкырыша башласа, әби әйтмешли, «өйне күчерәләр». Безгә көлешергә дә ярамый, аларга акырсалар-бакырсалар да сүз әйтүче юк. Зур булуы шундый рәхәттер ул. Без сеңелем белән көн саен үлчәшәбез. Кем күпме үскән дип. Тизрәк үсәсе килә. Аннары безне беркем дә әрләмәс иде.

Гөлназ һәм Гүзәл ЗӘКИЕВАЛАР.
Чаллы шәһәре.

* * *

МИН классташым Р.га гашыйк булдым. Ул шундый чибәр, акыллы. Күпме генә мине озатуын, миңа бәйләнүен көтсәм дә, һаман да бәйләнми үзе. Аптырагач, бер көнне дәрестә аңа карап утырдым. Елмайгалап та алдым. Аңлады, дисезме? Аңламады шул. Тәрәфескә чыккач, минем янга килде дә: «Нәрсә миннән көлеп утырасың әле син, колга тәре», — дип чәчне йолкып алды.

ГӨЛҮСӘ.
Сарман районы.

* * *

Күрше малае Артурга кызыгам. Вәт яши белә ул. Нинди генә уенчыгы, нинди генә киеме юк. Әтисе аңа әллә нинди тәмле әйберләр алып кайта. Кызыгам да инде шуларга. Минем дә булсын иде, шулай бай булсаң иде, дим. Ә әти белән әни үзара сөйләшкәндә гел: «Урлашмыйча гына баеп булмый шул ул»,— диләр. Алайса, Артурның әтисе урлаша инде. Әнигә: «Ә сез нишләп урлашмыйсыз соң?» — дигәч, «Урлашырга ярамый, улым»,— ди. Нишләп алай соң ул? Бай булырга ярый, урлашырга ярамый.

Р. КӘРИМОВ,
4 нче класс укучысы.
Әлмәт.

МӘКТӘП ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ КИРӘКМЕ?

ТОРМЫШЫБЫЗДА бик күп үзгәрешләр булды. Ләкин мәктәпләребезгә үзгәреш җилләре бик соңлап кына барып җитә шул.

Инде күптән хезмәт урыннарында бер эштән икенче эшкә күчкәндә характеристикалар алу туктатылды. Бу безне җитәкчеләребездән бәйсез итте. Ә мәктәпләрдә исә мондый характеристикалар язу әле һаман да дәвам итә. Кирәкме соң бу? Балаларыбыз дүртенче класска җиттеләрме, аларга укытучылары начар характеристика язу белән яный башлый. Бу күп кенә укучыларны укытучылары каршында куштанланырга, ялагайланырга мәҗбүр итә. Алай гына да түгел, аларның күбесе әләкчегә әйләнәләр. Мондый характеристикалар язу туктатылсын иде. Кирәкми безгә андый кәгазьләр. Мәктәп — ул белем учагы һәм балаларыбызга ул аң-белем, әхлакый тәрбия бирсен иде. Бары тик шул гына.

Әлфия САБИТОВА.
Яр Чаллы.



(шаян хикәя)

МАЛАЙНЫҢ йокы аралаш саташып сөйләнүеннән Мәүли шуны аңлады — мәктәпкә Хаммурапи патша килә икән! Аны икмәк-тоз белән каршы алырга каты әзерлек бара. Укучылар формаларын үтүклиләр, барабан тишекләрен лейкопластырь белән ямыйлар. Үткән айда Пушкинны каршы алганда тишелеп беткәннәрдер алар. Мәктәп директоры йөгерә-йөгерә Хаммурапи патшага тәхет ясый. Башкалар аның вәзирләрен утыртыр өчен мендәр тегәргә авыл өстеннән каз мамыгы җыя. Мәхшәр...

Инде ничәнче көн Мәүлинең малае шулай Хаммурапи исеме белән авыз чайкый. Ә иртән сорашсаң, берни белми. Үткән айда тәне буе: «Безнең авылны беренче булып Колумб ачкан», — дип сөйләнә-сөйләнә география китабы өстендә йоклады бит.

«Болай булмый, врачка күрсәтергә кирәк», — дип уйлады Мәүли һәм малаен больницага алып китте. Врач ишеге төбендә халык күп иде. Мәүли юан хатын янына чиратка басты.

— Улыгыз авырыймы әллә? — дип кызыксынды аның күршесе.

— Әйе, йоклый алмый, саташа. Үткән айда Колумб белән материклар ачып йөрде. Ә хәзер ниндидер патшаны каршыларга әзерләнә... — дип көрсенде Мәүли. — Уку программалары авыр шул хәзер. Башына зыян килде, күрәсең. Әйбәтләнсә ярый да. Бердәнбер улым иде...

— Хи-хи... Юкка борчыласың! Минем кызым да шулай саташа. Соңгы вакытта ул төне буе Чеховның сакалын тарый. Ачык дәрес алдыннан була мондый хәлләр. Укытучылары дәрес материалын берничә көн алдан һәр укучыга бүлеп бирә дә, безнең бахырлар, шуны ятлыйятлый, саташа ук башлыйлар. Синең малай белән дә шул ук хәл. Классларында тарихтан ачык дәрес буладыр аларның.

— Әйе, — дип баш какты Мәүли малае.

Юан ханым сүзенә ышанып, врачка күрсәтеп тормады Мәүли, улын алып кайтып китте.

Чынлап та, тарихтан ачык дәрес үткәч, малае Хаммурапи патша исемен телгә алмас булды.

Ләкин Мәүли иртә шатланган икән. Күп тә үтмәстән малае: «Баканың кан әйләнеше белән кешенеке арасында охшашлык бар»,— дип йоклаганда саташып сөйләнә башлады. Мәүлине тагын борчу биләде. Хәзер биологиядән ачык дәресләре була, күрәсең.

Гали ГАТАУЛЛИН.

ТАГЫН БЕР ШӘФКАТЬЛЕЛЕК ФОНДЫ

Кешелеккә куркыныч янаучы рак авыруы турында ишеткәнегез бардыр сезнең.

Шунысы кызганыч, мондый яман авыру билгеле булса да, аның нидән барлыкка килүе һәм аннан котылу юлы әле дә булса табылмаган.

Рак белән авыручыларның саны Татарстанда да арта бара. Безнең Казанда гына да бу авырудан күпме бала тилмерә, йөзләгән әти-әни хәсрәтләнә. Күптән түгел, әлеге әти-әниләр ракка каршы балалар фонды оештырдылар. Максатлары әлегә гади: шифаханәләрдә дәваланучы иллеләп авыру балага Кыш бабай күчтәнәчләре өләшү, концертлар күрсәтү... Кыскасы, сабыйларның күңелен күрү.

Әйе, бу, билгеле, шәфкатьлелекнең тары бөртегедәй бәләкәедер. Әмма без — сәламәт балалар, әти-әниләр, абый-апалар авыру сабыйларга караганда күбрәк. Бергәләшеп, берләшеп, кулыбыздан килгән кадәр шул сабыйларга ярдәм итәргә, әти-әниләренең сызланган җаннарын юатырга тиешбез.

Фонд белән элемтәгә керергә теләүчеләр өчен телефон: 76-39-03.

Ракка каршы балалар фондының исәп-хисап счеты: № 700394 в Советском отделении СХБ г. Казани МФО 265771.

Благотворительному противораковому детскому фонду.

БЕЛМӘМЕШ — БЕРЕНЧЕЛӘРНЕҢ ДУСТЫ

ШӘВӘЛИ, Чаткы, Кирлеманнәрне күбегез белә торгансыздыр. Ә менә Белмәмеш кем ул? 90 нчы мәктәпнең беренче класс укучылары укый-яза белсәләр, җавап бирерләр иде инде. Әлегә өйрәнеп кенә киләләр шул. Шулай да Белмәмешнең сорауларына җавап бирә алалар. Руфинә Ибраһим кызы укыта ла аларны. Ә Белмәмешнең андый укытучысы юк. Кулларын як-якка җәйгән дә, берни белмим мин дигәндәй, сорауларны яудырып кына тора. Сигез укучы бер Белмәмешне генә өйрәтерләр әле!

Әйе, әйе, беренче класта алар нибары сигез укучы: җиде малай һәм шулар арасында берданбер кыз Рамилә. Берәү генә булса да тырыш ул. Малайларны да уздырып укырга, язарга, рәсем ясарга өйрәнә.

Иҗекләрне куша-куша укырга өйрәнүче әлеге нәниләр газета-журналлар турында да беләләр икән. Күптән инде «Сабантуй» газетасына да язылып куйганнар. Орчык буйлы бу малайларга, кызларга сокланып утырдым мин. Җиләк-җимеш, яшелчә бакчаларында үзләре үстергән кочакка сыймас кабак-карбызлар турында сөйләгәннәрен дә елмаеп тыңлап тордым. Чыннан да, шундый малайлар үстергәч, яшелчәләр кечкенә булмас!

Әлегә җитеп торырмы бу бәләкәчләр турында? Бераз үскәч, тагын бер кабат очрашырбыз әле алар белән.

Г. НИГЪМӘТҖАНОВА.
Казан.



Яңа ел пьесасы

Катнашалар:

ГАЯЗ
ДАНИЛ
ИЛШАТ — укучылар
ИЛНУР
ЭЛЬВИРА

ЗӘБИДӘ АПА — укытучы
АЛЬБЕРТ — кунак малае
КЫШ БАБАЙ

1 пәрдә

Гаяз өйдә ялгызы. Яңа ел алды. Почмакта матур итеп чыршы бизәлгән. Тәрәзәдән ап-ак кар яуганы күренә. Әкрен генә моңлы көй ишетелә.

ГАЯЗ *(үйчан гына сөйләнә)*. Менә, Яңа ел да җитә. Тиздән Кремль курантлары төнге уникене сугарлар. Ә минем бу елда эшләп калдырасы эшләремнең очы-кырые күренми әле. И-их, яңа елны бер борчусыз, бәхет-шатлык белән генә каршылыйсы иде дә бит... Юк шул! Беренчедән, иң якын дусларым белән үпкәләштем. Дәрестә юри генә Данилның физика дәреслеген яшереп куйган идем, үзем дә онытканмын. Ә аның эчендә ашыгыч телеграмма булган. Әнисе кайткач ачуланган Данилны. Хәзер малайлар минем белән сөйләшмиләр дә, хоккейны да үзләре генә уйныйлар. Әй, бик кирәкләре бар иде!

Аның каравы, Эльвира исемле дустым бар минем. Көн саен укудан бергә кайта идек. Хәер, дус түгел инде ул! Аның белән күптән сөйләшкәнебез юк! Бик ачуым килде аңа. Беркөн мәктәптән чыккач, күпме көттем-көттем, ә ул юк та юк. Берзаман ни күрим, мәктәптән колга буйлы, ямьсез генә сипкелле бер «бульдозер» белән көлешә-көлешә чыгып килә! Киттем дә бардым, бик кирәге бар ие... Сөйләшмим дә хәзер.

Тагын бер зур кайгым бар — татар әдәбиятыннан чиреккә «ике»ле чыгардылар. Бу хурлыкка ничек түзим. Тәмам башлар каткан инде, нишләргә дә белгән юк!

Гаяз тәрәзәгә таянып, урамга карап уйга тала, шулчак ишектә кыңгырау шалтырый. Данил, Илшат, Илнур керәләр.

ДАНИЛ. Сәлам, Гаяз!

ИЛШАТ. Нихәлләрдә яшисең?

ИЛНУР. Сәлам!

ГАЯЗ *(борылып карамыйча гына)*. Әле кичә генә сөйләшми дә идегез, хәзер нихәлләрдә яшисең, имеш!

ДАНИЛ. Гаяз, ярар, нитмә, борчылма, мин сине гафу иттем инде.

ГАЯЗ. Ә минем синнән гафу үтенгәнем дә юк, белдеңме!

ИЛНУР *(ачуы чыгып)*. Кара, кара моны, кеше монда аның янына дуслашырга дип кергән, ә ул нишли!

ИЛШАТ. Ташлагыз әле, малайлар! Әйдә, Гаяз, лутчы бүген булачак маскарадка яңа номер әзерлибез. Без икәү гитарада, Данил баянда уйнар, Эльвираны җырлатырбыз, ризамы?

ГАЯЗ. Уйный белмим мин гитарада!

ИЛШАТ. Бәй, миңа ияреп кенә барырсың.

ГАЯЗ. Синең гитаристлыгың да шул минем әбинең футболистлыгы хәтле генә инде...

ИЛНУР *(бөтенләй ярсып)*. Малайлар, точно, мин аның ишек шүрлегенә менеп төшәм хәзер!

ДАНИЛ. Ярар, Гаяз, бигайбә, бездән калмады, кердек, чын күңелдән сөйләшергә теләдек, чынлап сөйләшүне аңламыйсың икән инде, анысы синең эш!

Чыгып китәләр.

ГАЯЗ *(еларга җитешеп)*. Яңа елны дусларсыз гына каршылыйммы инде? Нишләдем мин, нишләдем! *(Елап, мендәргә каплана. Шулчак күк күкрәгәндәй гөрелте ишетелә, кыңгыраулар чыңлый, җил улаганы ишетелә, Кыш бабай килеп керә).*

КЫШ БАБАЙ. Елама, Гаяз, мин синең күңелең керсез икәнен белеп, сиңа ярдәм итәргә килдем.

ГАЯЗ *(башын күтәреп)*. Ничек, бабакай?

КЫШ БАБАЙ *(алтын таягын күтәрә)*. Күрәсеңме, бу — алтын таяк. Аның ярдәмендә вакытны кире чигерергә була. Мин хәзер вакытны ун көнгә кирегә чигерәм. Ялгышларыңны төзәтергә була әле сиңа!

Кыш бабай таягы белән идәнгә суга. Сызгырган тавыш ишетелә. Пәрдә ябыла.

2 пәрдә

Гадәти класс. Әдәбият дәресе бара. Данил белән Гаяз, Илшат белән Илнур утыра. Укытучы Зәбидә апа дәрес аңлата. Малайлар, дәрес тыңламыйча, шаярышып утыралар.

ЗӘБИДӘ АПА. Шулай итеп, укучылар, без узган дәрестә Фатих Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун» исемле поэмасын өйрәнгән идек. Бүген чиреккә билге чыгара торган көн. Яле, Гаяз, ике ай буе рәтле билге алганың юк, сөйлә әле безгә шул поэманың эчтәлеген.

ГАЯЗ *(торып басып, китапка күз йөгертә башлый)*. Эһем... Ни... Бакча эчендә госпиталь...

ЗӘБИДӘ АПА. Яле, такта янына чык, алайса, күзең китапта гына!

ГАЯЗ *(чыга, өметле күзләр белән Данилга карый, малайлар тырышып-тырышып, куллары белән моңа аңлаталар)*. Эһем... Бакча эчендә госпиталь, кәрнизләре челтәрле була.

ЗӘБИДӘ АПА. Шуннан, шуннан?

ГАЯЗ. Короче... *(Данилга карый, Данил хат язган кебек хәрәкәтләр ясый)*. Фазыл бер кызга хат яза.

ЗӘБИДӘ АПА. Әйе, әйе, дөрес.

ГАЯЗ *(Данил аңа гармун тарткан кебек ишарә ясый, Гаяз аны дөрес аңламый)*. Егет авыру булса да, спорт белән шөгыльләнә, эспандер тарта...

ЗӘБИДӘ АПА. Нәрсә? Нинди эспандер?!

ГАЯЗ. Эһем... *(Данилга карый, тегесе пидер пышылдый, «егет янына бер кыз килә» дигәнне, ... Гаяз ишетми, аптырагач, Данил яулык бәйләгән к... кылана)* Эһем... Шулчак бер әби килеп чыга.

Көлешәләр.

ЗӘБИДӘ АПА. Әйе, Гаяз, күренеп тора синең ничек укыганлыгың! Ярый, сиңа өстәмә сорау. Чирек билгеңне шул хәл итәчәк. Җавап бир, нәрсә ул Ватан?

ГАЯЗ *(бик озак уйлап тора, аптырап бетә)*. Бе-бе-белмим...

ЗӘБИДӘ АПА. Илшат, сиңа шул ук сорау!

ИЛШАТ *(чатнатып)*. Ватан ул — туган ил, туган җир, туган авыл, әти, әни!

ЗӘБИДӘ АПА. Молодец! Яле, кабатла Гаяз.

ГАЯЗ. Ватан ул — туган ил, туган җир, туган авыл, Илшатның әтисе һәм әнисе.

Көлешәләр.

ЗӘБИДӘ АПА *(ачуы чыгып)*. Булды Гаяз! Туйдым мин синең бу кыланышларыңнан, миннән бүтән рәхим-шәфкать көтмә! Ә чирегеңә — зу-ур «ике»ле!

Кыңгырау шалтырый. Һәммәсе дә чыгып китәләр. Гаяз гына басып кала.

ГАЯЗ. Бетте! Барысы да бетте, өйдәгеләрнең күзенә ничек кайтып күренергә? Нәрсә-нәрсә, әмма әдәбияттан «ике»ле чыкканны белсә, әти каеш белән тотып ярачак мине! Уф! Нишлим, нишлим?

Янә күк күкрәгән, кыңгырау чылтыраган, җил улаган тавыш ишетелә, Кыш бабай килеп керә.

КЫШ БАБАЙ. Тагын ялгыштыңмы, Гаяз?

ГАЯЗ. Ялгыштым, бабай! Нишлим?

КЫШ БАБАЙ. Һай, Гаяз, бик яшь шул әле син, гел бәлаләргә тарып кына торасың. Эльвираны үпкәләттең, «ике»ле эләктердең, әле тагын бер-ике көннән дус малайларың белән дә кычкырышачаксың.

ГАЯЗ. Ничек? Данил, Илшатлар беләнме? Иң якын дусларым ич алар минем! Булмас!

КЫШ БАБАЙ. Әйе, Гаяз. Тик ничек икәнен мин сиңа әйтә алмыйм. Бу — бөек вакыт сере. Мин бары тик вакытны кирегә чигереп кенә сиңа булыша алам. Рәхим ит, тагын ун көнгә артка!

Кыш бабай таягы белән идәнгә суга, сызгырган тавыш ишетелә. Пәрдә ябыла.

3 пәрдә

Елга буе. Көн якты. Кар. Гаяз бәкедән балык тотып утыра.

ГАЯЗ. Балык кап, яр башында ялтырап ят, эләкми шул балыгы да. Бер килмәсә килми бит ул, бүгеннән башлап, Эльвира белән сөйләшмим дә! Йөрсен әнә шул сипкеллесе белән! *(Торып баса, кулын маңгаена куя)*. У-у, бер көтү халык килә болайга таба, тимераякта шуарга, хоккей уйнарга төшәләр инде болар. Кара, безнең малайлар ич болар! Чү! Эльвира белән теге малай да килә түгелме? Көлешкән булалар. Китим микән әллә моннан яхшы чакта? Ә, юк, күреп алдылар, әнә, Илшат кәшәкәсен болгый-болгый болайга йөгерә.

Дөбердәшеп бер көтү бала-чага керә.

ИЛШАТ. У-у, Гаяз, ничек, балык чиртәме?

ИЛНУР. Безгә әйтмичә генә төшеп киткән, юньсез!

ЭЛЬВИРА. Гаяз, ә мин сине хәзер бер малай белән таныштырам. *(Ике малай арасына баса)*. Гаяз, бу — Альберт. Альберт, ә бу — Гаяз. Малайлар, сез сөйләшә торыгыз, яме! Мин конькины гына киеп киләм *(китә)*.

ГАЯЗ. Бик кирәгең бар иде!

АЛЬБЕРТ. Сәлам! Гаяз дигән егет син буласыңмы инде?

ГАЯЗ. ...

АЛЬБЕРТ. Хм... Телсез мәллә син?

ГАЯЗ. Әйе.

АЛЬБЕРТ. О-о... Менә ич, сөйләшә дә беләсең икән. Мин Альберт булам. Шәһәрдән кунакка кайттым.

ГАЯЗ. Безнең авылныкы түгеллегең күренеп тора инде.

АЛЬБЕРТ. Каян күренә?

ГАЯЗ. Бездә бүрекне алай өскә күтәреп бәйләмиләр. Менә минем шикелле артка бәйләп куялар.

Альберт көлә дә бүреген Гаязныкы төсле итеп бәйләп куя.

АЛЬБЕРТ. Булдымы?

ГАЯЗ. Булмады. Барыбер безнең авылныкы түгел син!

ИЛШАТ. Ташлагыз әле, малайлар, әйдәгез, лутчы хоккей уйныйбыз.

ГАЯЗ. Уйнамыйм мин *(әйберләрен җыя да китәргә кузгала, башкалар аны уратып ала)*.

ДАНИЛ. Гаяз, кая барасың?

ИЛНУР. Әнисен сагынган ул.

ДАНИЛ. Тукта, көлмә инде кешедән.

ГАЯЗ. Бик кирәгегез бар иде!

ИЛНУР. Гаяз, тыңла, бер мәзәк сөйлим. Урман буйлап куян чаба икән. Бер аю туктаткан моны.

— Кая ашыгасың, кылый, — дип сораган.

— Менә, арыслан шундый закон чыгарган, кемнең тәпие бишәү, берсен кисәчәкләр ди.

— Ник куркасың, — дигән аю, — синең тәпиең дүртәү генә бит?

— Шулай үзе, — дигән куян, — әмма бу эшне арыслан ишәккә тапшырган, ә ул башта кисә, аннары гына саный... Кайтасың килгәч, бар кайт, Гаяз, әмма өеңә кайтып, телевизорны кабызып, диванга сузылып яткач, яхшылап уйла бу мәзәк турында!

Гаязның ялгызын гына калдырып чыгып китәләр.

ГАЯЗ. Миңа берегез дә кирәкми! Ишәк, имеш, арыслан имеш! Тукта, Илнур нәрсә әйтергә теләде соң моның белән? Мин, шулай итеп, башта кисәм, аннан соң гына саныйммыни? Ишәк ул мин мени? *(Куллары белән башын тотып җиргә утыра).*

Гөрелте, кыңгырау, җил тавышлары ишетелә, Кыш бабай керә.

КЫШ БАБАЙ. Их, Гаяз, синең авыр хәлдә калуыңны ишетеп, мин сиңа ике тапкыр ярдәм кулын суздым. Чөнки күңелең керсез иде. Күрәм, ярдәм иткән саен син юньсезләнә генә барасың, киребеткән бер малайга әйләнә башладың. Әле син бу чиректә әдәбияттан «ике»ле чыгачагын да, Яңа елны дусларыңнан башка гына каршылыйсыңны да белми торгансыңдыр.

ГАЯЗ. Нишләргә соң миңа, бабакай?

КЫШ БАБАЙ. Ярый, мин сиңа тагын бер кабат булышып карыйм. Вакытны алгамы, арткамы күчерим?

ГАЯЗ *(кинәт)*. Кирәкми! Үзем! Үзем тырышам, үз язмышымны үзем хәл итәм! Рәхмәт сиңа, бабакай, тик мин үзем, яме, үзем!

КЫШ БАБАЙ. Ярый, Гаяз, мин китәм, сиңа уңышлар, ак юл телим! Онытма, Гаяз, бәхетең үз кулыңда!

Кыш бабай югала, сәхнәгә малайлар һәм кызлар килеп керә.

ГАЯЗ. Дуслар! Малайлар, кызлар! Гафу итегез мине! Альберт, син дә гафу ит, дорфа сөйләштем...

ЭЛЬВИРА. Минем абый үпкәли белми ул.

ГАЯЗ. Нинди абый?

ЭЛЬВИРА. Гап-гади, туганнан-туган абый. Шәһәрдән безгә кунакка кайтты ич, кичә генә, әле бит юньләп танышырга да өлгермәдегез, их сез, калай әтәчләр!

ГАЯЗ *(үзалдына)*. Ә мин чак кына Эльвира белән үпкәләшми калдым. Эльвира! Син дә ачуланма, яме, *(малайларга)* Данил, Илшат, Илнур, сез минем иң якын дусларым, моннан соң да шулай булып калыйк, яме!

ИЛШАТ. Бәй, әйттем бит инде, юк белән баш катырасың дип.

ДАНИЛ. Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсачы!

ИЛНУР. Ә сиңа әдәбияттан бик тырышып әзерләнергә кирәк булачак. Зәбидә апа миңа сер итеп кенә әйтте, киләсе дәрестә Гаяздан сорыйм, диде.

ГАЯЗ. Мин аны өйрәндем инде, сөйләп күрсәтимме?

БАШКАЛАР. Яле, яле!


ГАЯЗ. Саратский яшел гармун,
Көмеш кыңгыраулары,
Шул көмеш кыңгырауларның
Кичке яңгыраулары

Әллә нишләтә күңелне,
Үксеп елыйсы килә.
Елау егет эшемени,
Эх, бер җырлыйсы килә!

Һәммәсе дә җырлыйлар.

Пәрдә.

Алмаз ГЫЙМАДИЕВ





ҺӘР ЭШНЕҢ ҮЗ ЯМЕ



ГАЗЕТАБЫЗНЫҢ якын дуслары һәр төбәктә бездә. Чаллы якларында да бар андый дусларыбыз. Миркадәм Матшин — нәкъ менә шуларның берсе. Мәсәлән, бу ак шәһәргә терәлеп торган Тукай районында «Сабантуй» газетасын киләсе елны алты йөзләп бала алдырачак. Әлеге күркәм санга ирешүдә Миркадәм абыйның өлеше зурдан. Госстрахта эшләүче кеше буларак, ул матди яктан кыенлык кичерүче ялгыз әби-бабайларга, авыру балаларга ярдәм кулы суза, аларның тормышына ямь өстәргә тели. Миркадәм абый Тукай районының инвалидлар җәмгыяте рәисе булып тора. Ул үзе турыдан-туры биш ялгыз әбине шефлыкка алган. Бу җәмгыять ике йөзләп балага киләсе елга «Сабантуй»ны бүләк итеп яздырган.

Гомумән, М. Матшин балаларны ярата. Шушы мәхәббәт хисе аңа кулына каләм алырга мәҗбүр итә. Нәни дуслары өчен шигырьләр, әкиятләр иҗат итә, көйләр язып карый. Авторның күп кенә әсәрләре беренче булып безнең газетада дөнья күрде.

Тумышы белән ул үзе Мамадыш төбәгеннән. Көек-Ерыкса авылында туып-үскән. Авылда җиденче классны тәмамлагач, педучилищеда белем ала. Укытучы булып эшли. Эшкә уңган, сәләтле бу егетне бик тиз күреп алалар. Ул елларга хас булганча, кайда кыен, кайда авыр — аны шунда җибәрәләр. Миркадәм абый комсомол, партия, совет органнарында җигелеп эшли, хуҗалык эшен башкара. Кайда гына булмасын, үз хезмәтеннән ямь һәм матурлык таба.

Күптән түгел генә ул үзенең күркәм бәйрәмен билгеләп узды. Күпсанлы дуслары аны 60 яше тулу белән тәбрик иттеләр. Без дә аларның шушы изге теләкләренә кушылабыз, «Күңелегездә һәрвакыт матурлык һәм игелек хисе яшәсен!» — дибез. Газетабыз үзенең якын дустын махсус дипломыбыз — «Сабантуй» бүләге белән бүләкли.

Г. САДӘ.

Рәсемдә: Миркадәм МАТШИН.
Рәссам Рәис ШАҺИЕВ рәсеме.

ЧЕБЕН, ЧЕРКИ ҺӘМ БАКА

(Әкият)

Чебенгә черки кунган,
Чебен кәефен җуйган:

Очып китәм дигәндә,
Килеп төшкән түшәмгә.

Аннан очкан урамга,
Юлыккан ул буранга.

Килеп кергән арыкка,
Арыктагы ярыкка.

Ярыкта ул кышлаган,
Туны җылы — тышланган.

Язлар килгән, боз киткән,
Кыңгыраулы җәй җиткән.

Чебен, черки уянган,
Ерак юлга кузгалган.

Юллары ерак булган,
Юлда бер күл тап булган.

— Әйдә, туктап ял итик,
Ашау ягын хәл итик, —

Чебен әйткән фикергә
Риза булган черки дә.

Аста зәңгәр күл икән,
Төнбоеклы ил икән.

Ничек төшми китәсең!
— Кузгалырбыз иртәсен.

Төнбоекка кунганнар,
Ой, вай... харап булганнар.

Бака шунда тел сузган,
Чебен, черки
юк булган.



Йә, чикерткә сөйләп бир,
Син бит җырчы, спортчы,
Кайда, ничек укыдың,
Кемнәр синең булышчы?

Чикерткәбез оялды —
Сикерде дә югалды.

КАР ӨЙ

Ак кардан өйләр салам,
Тәрәзә, ишек куям,
Килсеннәр дә күрсеннәр,
Оста кул дип белсеннәр.

Бу өйләргә кем керер,
Кем керер дә, кем торыр?
Шуны да белмисезме?
Ак сакаллы кыш торыр!

КОШЛАР КАНАТ КАГЫНА

Алтмыш тавык, алты әтәч
Җир сөрәләр чүплектә,
Тум-түгәрәк йомырканы
Тәгәрәтеп читлектә.

Җыр сузалар, моң сузалар
Тамчы-тамчы су йотып,
Балаларның авызыннан
Матур көйләрне отып.

Җилфер, җилфер җил искәндә
Кошлар канат кагына.
Алты әтәч, алтмыш тавык
Җилдә таган атына.

Миркадәм МАТШИН

ТАУЛАР, ТАУЛАР




Таулар, таулар, таулар,
таулар —
Бормалыдыр юллары.
Юллар кебек борма-борма
Кешеләрнең уйлары.

Таулар, таулар, таулар,
таулар —
Тау башлары чалмалы.

Дөнья иркен, дөнья чиксез,
Кеше гомере чамалы.

Күңелем булмый, җаным
тынмый,
Тауларыма бармасам.
Нишләр идем, таулар кебек,
Горурланып янмасам.



ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕНДӘ

Яшел чыршы тирәсендә
Үткәрербез зур бәйрәм.
Җырларбыз да биербез,
Уйнарбыз әйлән-бәйлән.


Ерак кара урманнардан
Кунаклар килер әле.
Төлке, бүре, аюы да
Бүләкләр бирер әле.

Чыршыбызда ут
кабынгач,
Кар бабай килеп керер.
Кар кызы да безнең белән
Уйнап һәм биеп йөрер.

Илзирә НАСЫЙБУЛЛИНА.
Тукай, Суыксу.

Рәсемнәрдә: Казандагы 17 нче мәктәпнең 1 класс укучысы Саша Корунов Яңа ел чыршысын бизәп тә куйды инде. Бу чыршылар да Яңа елны көтәләр.

А. КОЛСАНОВ һәм М. ШАКИРҖАНОВ фоторәсемнәре.



КЕМ ИГЪТИБАРЛЫРАК?

Чыршыдагы охшаш шарларны табыгыз.

Баш мөхәррир
Роберт МИҢНУЛЛИН

Редколлегия: Шәүкәт ГАЛИЕВ, Атлас ГАФИЯТОВ, Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ, Ләлә ГЫЙМАДИЕВА (җаваплы секретарь), Госман САДӘ (баш мөхәррир урынбасары).



«Сабантуй»ны оештыручылар — Татарстанның Халык Мәгарифе министрлыгы, Яшьләр оешмалары советы, Балалар фонды һәм редакциянең хезмәт коллективы. 1924 — 90 елларда «Яшь ленинчы» исеме белән чыкты.

Индекс — 54124. Тираж 21695



Адрес: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.

Телефоннар:
53—07—86, 53—07—88,
53—07—90, 53—07—94,
53—07—77, 53—57—37.

Ярдәм итәргә теләсәгез: р/счет 700161998/2345716 в Волжско-Камском акционерном банке РКЦ ГЦБ г. Казани МФО 265005 «Для фонда редакции».



Заказ 1289 Газета Татарстан Информация һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 75.

Басарга кул куелды 1993 ел, 13 декабрь, 15 сәгать.